ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
Кама Тамагы
муниципаль районының
**Варварино авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты**

Кама Тамагы районы,
Варварино авылы
тел. 8-84377- 32-6-09

РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
Камско-Устьинский
муниципальный район
**Исполнительный комитет**
**Варваринского**
**сельского поселения**
Камско-Устьинский район,
с. Варварино
тел. 8-84377- 32-6-09

---

# КАРАР

**“04” сентябрь 2018 ел** **№ 5**

**Җирле референдум үткәрү**
**инициативасы турында**

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында”гы Федераль законның 15 маддәсе, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы “Җирле референдум турында”гы Татарстан Республикасы Законының 17 маддәсе, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Уставының 15 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР КЫЛА:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге территориясендә түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:
"Сез 2019 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Варварино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча

теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, армиядә хезмәт итүче 1 төркем инвалидларыннан, көндезге формада укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча киләсе эшләрне башкаруга тоту белән килешәсезме:

*** - җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге**:

–Төньяк, Левоовражная, Правоовражная, Үзәк, Көньяк урамнары буенча Көрәле авылы юлларын ремонтлау;

- Варварино авылында Ленин урамы буенча юлларны ремонтлау;

*** зираттагы күмү урыннарын тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру**:

- Көрәле авылы зиратыннан чүп-чарны җыю һәм чыгару;
- Варварино авылы зиратыннан чүп-чарны җыю һәм чыгару;

*** җирлек торак пунктлары чикләрендә территорияләрне төзекләндерүне оештыру**:

- Көрәле, Варварино авыллары эчендә чүп үләннәрен чабу (җәйге-көзге чор).

**- янгын куркынычсызлыгы**

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Варварино авылы, Ленин урамы, 28 йорт,
- Көрәле авылы, Үзәк урам, 2а йорты,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” рәсми сайтының мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районының**
**Варварино авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Т.Нотфуллин**